ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм $2^1$ статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2007, № 4; 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 5, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда «"Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында"» сүзләреннән соң «1991 елның 19 апрелендәге 1032-I номерлы» сүзләрен өстәргә;

2) $2^1$ статьяда:

а) 3 өлешнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«(2) эштән җибәрү куркынычы янаган гражданнарны, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗ һәм эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче гражданнарны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү программаларын, шул исәптән инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыруны да кертеп, халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү чараларын күздә тота торган дәүләт программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;»;

б) $3^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$3^1$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты хезмәт ресурслары өстенлекле җәлеп ителә торган Россия Федерациясе субъектларының Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлегенә кертелмәгән Россия Федерациясе субъектлары хезмәт ресурсларын җәлеп итү өчен шартлар тудыруны күздә тота

торган дәүләт хезмәт ресурслары мобильлеген арттыру программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга хокуклы. Дәүләт программасы әлеге программада катнашу турында Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, дәүләт идарәсе функцияләрен башкаручы органы тарафыннан хезмәт ресурсларын җәлеп итү ихтыяҗы булган эш бирүчеләр белән төзелгән килешүләрне (алга таба әлеге статьяда – килешү) исәпкә алып әзерләнә. Килешү дәүләт программасына кертелергә тиешле эш бирүчеләрне сайлап алу үткәрелгәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм дәүләт программасына кертелергә тиешле эш бирүчеләрне сайлап алу критерийларын исәпкә алып, дәүләт программасы расланганчы төзелә. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан түбәндәгеләр билгеләнә:

1) дәүләт программасына кертелергә тиешле эш бирүчеләрне сайлап алу тәртибе һәм критерийлары;

2) эш бирүчеләрне дәүләт программасыннан төшереп калдыру тәртибе;

3) дәүләт программасында катнаша торган эш бирүчегә Россия Федерациясенең башка субъектларыннан эшкә урнаштыру өчен хезмәткәрләр җәлеп итү максатларында финанс ярдәме күрсәтү тәртибе;

4) ярдәм чаралары исемлеге, аңа дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясенең башка субъектыннан эшкә урнаштыру өчен җәлеп ителгән хезмәткәрләргә бирелә торган, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, дәүләт идарәсе функцияләрен башкаручы органы белән килештереп, эш бирүче тарафыннан билгеләнүче ярдәм чаралары кертелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $3^2$ өлеш өстәргә:

«$3^2$. Килешү эчтәлегенә карата таләпләр «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-I номерлы Россия Федерациясе Законында билгеләнгән. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты килешүнең өстәмә шартларын, шул исәптән эшкә урнаштыру өчен җәлеп ителә торган хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын яңа урында урнаштыруга бәйле шартларны да билгеләргә хокуклы.»;

г) түбәндәге эчтәлекле $3^3$ өлеш өстәргә:

«$3^3$. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты эшкә урнашу өчен Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча авыл җиренә күченә торган эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына өстәмә финанс ярдәме билгеләргә хокуклы.»;

д) 4 өлештә:

4 пунктның дүртенче абзацында «"Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында"» сүзләреннән соң «1991 елның 19 апрелендәге 1032-I номерлы» сүзләрен өстәргә;

6 пунктта:

унөченче һәм ундүртенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыру;»;

түбәндәге эчтәлекле $10^1$ – $10^6$ пунктлар өстәргә:

«$10^1$) Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында законнар нигезендә чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану хакында бәяләмәләр бирү;

$10^2$) эш бирүчеләргә дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында хезмәт ресурсларын җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү;

$10^3$) дәүләт халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү программасына инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыру чараларын кертү өчен тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу;

$10^4$) эш бирүчеләрне инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати тәэмин итү;

$10^5$) инвалидларны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәткәндә булышуны оештыру максатларында федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре һәм эш бирүчеләр белән үзара эшләү;

$10^6$) эшчәнлек өлкәсе (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында инвалидларга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көчләренә керүнең башка сроклары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 2 пунктының «а» пунктчасы, «д» пунктчасының бишенче, алтынчы, унынчы – унөченче абзацлары 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 08 декабрь
№ 99-ТРЗ